ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘТӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423737, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75 а йорты

СОВЕТ АТЯСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423737, село Атясево, ул. Центральная, д. 75 а

**КАРАР**
**17 .09.2019**

**РЕШЕНИЕ**
**№19**

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел,№ 67-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Әтәс авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Советы

**Карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә:

"2020 елда бер тапкыр түләнә торган салымның 18 яшькә җиткән, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр гражданнан, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәткә бәйсез рәвештә, 2020 елда бер тапкыр түләү кертүгә сез, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 1 төркем инвалидлардан (аларның саны җирлек халкының гомуми санынннан 30 процентан да артмый), җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, 500 (биш йөз) сум күләмендә килешәсезме?, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

- су челтәрләрен ремонтлау, тоту, су чыганакларын лицензияләү;
-урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;
-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдлау, кардан чистарту)
-йорт төзелеше һәм ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;;
- зират коймасын ремонтлау;
- Күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
-рәсми спорт һәм мәдәни чараларны оештыру һәм уздыру;;
- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;
- һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү, обелиск төзү;;
- Бикчәнтәй авылындагы ФАП бинасында су белән тәэмин итү һәм чокырны төзекләндерү;;
- гидротехник корылмаларга декларацион тикшерү үткәрү.

“ӘЙЕ “ “ЮК”

2. Әлеге карар махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган: ТР, Актаныш муниципаль районы, Әтәс авылы, Үзәк урам, 75а йорты, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Әтәс авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Э.Ф.Насыйрова